# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2026 елда Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы Әсәй
авыл җирлегенең Митрәй торак пунктында
гражданнарга үзара салым кертү турында

**5 ноябрь 2025 ел. №2**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлегенең Митрәй торак пунктында гражданнар җыены

**карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлегенең Митрәй торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан, аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2026 елда 400 сум күләмендә үзара салымны кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1). Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту
(Яшьләр, Тукай, Подгорная, Мәктәп урамнарындагы вак таш юлларны профильләштерү, тыгызлау);

2). Су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне (су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау һәм карап тоту, материаллар, җайланмалар сатып алу, тишелешләрне бетерү, торбаларны алмаштыру)тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

3). Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (триммер һәм трактор өчен запас частьләр һәм ягулык-майлау материаллары сатып алу, үлән чаптыру, юлларны һәм территорияләрне кардан чистарту).

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» http://aznakaevo.tatar.ru., Әсәй авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.:
- Азнакай районы, Митрәй ав., Тукай ур., 15А.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Әсәй авыл җирлеге Башлыгы Г.З. Дәминова